# “Сәләтле балачак - өметле киләчәк”

Галимнәр сәләтсез балалар юк, һәркемнең нәрсәгә дә булса сәләте, омтылышы була диләр. Билгеле бер яшьтә баланың танып - белү сәләте тиешенчә файдаланылмаса, алга таба аның бу сыйфаты бөтенләй югалырга мөмкин.

Балалар бик тиз үсә. Тик шуны истә тотарга кирәк: бүген без сәләт, омтылышларын үстерергә ярдәм иткәндә генә, алар мөстәкыйль яши, тормышта яңа үрләр яулый ала. Аеруча сәләтле балаларны эзләү, табу һәм тәрбияләү – ил өчен иң мөһим мәсьәлә. Талантлы яшьләр – җәмгыятьнең төп байлыгы. Талантлы бала һәрвакыт үзенең җәмгыятькә кирәклеген тоеп, алга таба зур эшләр башкара алуына ышанып яшәргә тиеш.

Сәләтле балалар белән эшләүнең төп максаты- аларның нәрсәгә сәләтле, һәвәс булуын исәпкә алып, киләчәктә эчке халәтенә туры килә торган эшчәнлек белән шөгыльләнү өчен юнәлеш билгеләүгә ярдәм итү.

Төп бурычлар:
- төрле өлкәләрдә сәләтле балаларны аерып алу, аларның психологиясен өйрәнү;
- ата – аналар белән бергәләп баланың үсешенә, сәләтен ачуга ярдәм итү;
- балаларга үз белемнәрен күтәрү өстендә эшләргә ярдәм итү,
- мәктәпкә әзерлекне яхшырту;
- районкүләм һәм республикакүләм иҗади бәйгеләргә әзерләү;

Безнең бакчабыз талантларга бик бай. Кече яшьтәге балалардан алып тәрбиячеләргә кадәр без иҗат чишмәсендә кайныйбыз. Бакчабызда балаларның иҗади сәләтләрен үстерү максатыннан төрле түгәрәкләр эшләп килә. Һәр елны республикакүләм “Йолдызлык”, “Сандугач”, “Минем яраткан Татарстан”, “Сәяр”, “Кызыл төлке”, “Җәлил укулары”, “Безнең йортыбыз- Татарстан” конкурс- фестивалләрендә, районкүләм “Күпмилләтле Лениногорск- Дуслык күпере”, “Лениногорск йолдызы”, “Туган як җыры” һәм район мәгариф идарәсе планы буенча әзерләнгән бәйгеләрдә бик теләп катнашабыз һәм мактаулы урыннар яулыйбыз.